**Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы**
**Починок-Кучук авыл җирлеге башлыгы**
**КАРАРЫ**

**05 ноябрь, 2025 ел** **№ 1**

**Кукмара муниципаль районы Починок-Кучук авыл җирлеге Чигайка авылында гражданнарның үзара салым чараларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены үткәрүне билгеләү турында**

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законның 45, 69 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Кукмара муниципаль районы Починок-Кучук авыл җирлеге Уставының 22 статьясы нигезендә карар бирәм:

1. 2025 елның 20 ноябрендә 14 сәгать 00 минутка Кукмара муниципаль районы Починок-Кучук авыл җирлегенең Чигайка авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыены үткәрүне билгеләргә. Гражданнар җыенын Кызыл Октябрь авылы, Совет урамы, 12 адресындагы шәхси йортта уздырырга.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга: «Сез 2026 елда Кукмара муниципаль районының Починок-Кучук авыл җирлеге Чигайка авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, 1 һәм 2 төркем инвалидларыннан; көндезге уку формасы буенча укучы укучылар һәм студентлардан (курсантлардан); 80 яшькә җиткән һәм аннан өлкәнрәк затлардан; Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә сроклы хәрби хезмәткә чакырылган затлардан; Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә хәрби хезмәткә чакырылган затлар һәм аларның гаилә әгъзаларыннан кала, 1000 сум күләмендә үзара салым кертү белән һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

- тышкы урам яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм аларга бирелгән башка подстанцияләрне һәм мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җиһазларны ремонтлау;

- су белән тәэмин итү һәм су агызу системаларын, су суырту манараларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортлауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итә торган инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау;

- коеларны төзү, ремонтлау һәм аларга якын территорияне төзекләндерү;

- җир асты суларының табигый чыгу урыннарын (чишмәләрне) төзекләндерү;

- янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итү;

- торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту;

- торак пунктның башка территорияләрен төзекләндерү;

- тукталыш комплексларын ремонтлау, сатып алу һәм урнаштыру;

- традицион күмү урыннарын төзекләндерү, коймалар кору, ремонтлау.

«РИЗА» «КАРШЫ»

3. Гражданнар җыенын үткәрү өчен, торак пунктта яшәүчеләрнең исемлеген территориаль билге буенча (урамнар буенча) бүлү.

4. Починок-Кучук авылы башкарма комитетын гражданнар җыенын оештыручы итеп билгеләргә.

5. Әлеге карарны мәгълүмат стендларында һәм Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында «Авыл җирлекләре» бүлегендә кабул ителгәннән соң 5 көн эчендә урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

6. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Починок-Кучук авыл җирлеге башлыгы И.А. Йосыпов